ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

КАРАРЫ

2023 ел, 26 июнь №186

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2023 елның 13 июнендәге N258-ФЗ номерлы “Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының 2023 елның 30 гыйнварындагы 152 номерлы “Татарстан Республикасы Апас муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау турында” карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

18.3 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“коррупцияне һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсе яки “Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге N 273-ФЗ Федераль законның 13.4 статьясына ярашлы рәвештә Россия Федерациясе Президенты Администрациясенең вәкаләтле бүлеге тарафыннан үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре нигезендә;”.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырырга.

3.Бу карарның үтәлешен контролләүне Башлык урынбасары Л.Т. Хантимировка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башлыгы- Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы Рәисе-

А.Г. Җиһаншин